ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№120**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**01.02.2021**

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законына, 1996 елның 12 гыйнварендәге «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ санлы Федераль законына, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 73 номерлы карарына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2021 елның 01 февраленнән, 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә, 6 424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. 2021 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнварындагы 150 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)урнаштырырга һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
01.02.2021 №120

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә 01.02.2021 елдан
җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китереп җиткерү | 3501,30 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару. | 997,40 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1926,28 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
01.02.2021 №120

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә 01.02.2021 елдан
җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге бәяләре

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гыйбәдәт киеме кидертү/ Кәфенләү | 618,59 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 2882,71 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 997,40 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 1926,28 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |